РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№ 134**

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» Муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 нче елның 24 нче гыйнварындагы 71 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» Муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 10.02.2020 елның 134 номерлы карарына кушымта

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү»
Программасы

## 1. Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның Исеме | «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» |
| Программаның нигезе һәм норматив тәэмин ителеше | «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризм һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру» Дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карары (2014 елның 1 ноябрендәге редакция) |
| Программаның заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүчеләр | Кукмара муниципаль районы Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе |
| Программаның төп башкаручылары | Кукмара муниципаль районы Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе<br>Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе<br>Балалар белем бирү-сәламәтләндерү үзәге<br>«Зилант» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе<br>«Ялкын», «Атлант» спорт юнәлешендәге яшүсмерләр клублары<br>«Кукмара РҮХ» МБУЗ<br>Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы<br>Кукмара муниципаль районында ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы<br>Кукмара муниципаль районы Мәдәният идарәсе<br>Инфраструктура үсеше идарәсе<br>Район хәрби комиссариаты<br>Район эчке эшләр бүлеге<br>Авыл җирлекләре<br>Предприятие, учреждениеләр, оешмалар, иҗтимагый оешмалар<br>«Хезмәт даны» район газетасы редакциясе<br>ТРК «Кукмара авазы» |
| Программаның максатлары | Районда физик культура, спортны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.<br>Халык арасында массакүләм һәм индивидуаль физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшенең үсеше өчен шартлар тудыру, сәламәт яшәү рәвешен раслау, халыкның сәламәтлеген яхшырту. |
| Программаның бурычлары | 1. Массакүләм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, районның спорт имиджын үстерү.<br>2. Яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, аның иҗади потенциалын районның көндәшлеккә сәләтлелеген ныгытуда куллану, яшь буынның тормыш сыйфатын күтәрү өчен оптималь шартлар булдыру.<br>3. Яшьләр һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү.<br>4. Район яшьләренә патриотик тәрбия бирү системасын үстерү |

| | |
|---|---|
| | һәм модернизацияләү. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү»<br>2. «2018 – 2020 елларга балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм мәшгульлеген оештыру»<br>3. «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының авыл яшьләре»<br>4. «2018 — 2020 елларга яшьләрнепатриотик тәрбияләү» |
| Программаны ресурслар белән тәэмин итү | Программа республика һәм муниципаль бюджетлар, бюджеттан тыш чыганаклар, ведомство карамагына бәйсез рәвештә предприятие һәм оешмалар акчалары хисабына тормышка ашырыла. |
| Программаны тормышка ашыру механизмы | Программаны тормышка ашыруны координацияләү һәм контрольдә тоту өчен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы Физик культура һәм спорт буенча Координация советыт төзелә. |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленеп, программаны финанслау күләме | 2018 – 2020 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына 163 130,7 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2018 ел – 22 897,9 мең сум;<br>2019 ел – 69 665,6 мең сум;<br>2020 ел – 70 567,2 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга кадәр түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>физкультура һәм спорт өлкәсендә:<br>халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халыкның өлешен 44% ка кадәр;<br>укучылар һәм студентларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче укучылар һәм студентларның өлешлен 61% ка кадәр;<br>Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче инвалидларның әлеге категориядәге халыкның гомуми санындагы өлешен 13% ка кадәр;<br>спорт объектларының бер үк вакытта үткәрүчәнлек сәләтен 36,33 процентка кадәр;<br>спорт корылмалары санын 165 кә кадәр;<br>яшьләр сәясәте өлкәсендә:<br>балаларны һәм яшьләрне 40% ка кадәр оештырылган ял итү формалары белән колачлау;<br>балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү юнәлешендәге чаралар белән 6500 гә кадәр кеше колачлау |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 10.02.2020 елның 134 номерлы карарына 1 нче кушымта

**«2018 – 2020 ЕЛЛАРГА**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА**
**ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТНЫ ҮСТЕРҮ»**
**ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫ**

**1. Ярдәмче Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» |
| Ярдәмче программаның нигезе һәм норматив тәэмин ителеше | «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризм һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру» Дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карары (2014 елның 1 ноябрендәге редакция) |
| Ярдәмче программаның заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны эшләүчеләр | Кукмара муниципаль районы Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе |
| Ярдәмче программаның төп башкаручылары | Кукмара муниципаль районы Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе<br>Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе<br>Балалар белем бирү-сәламәтләндерү үзәге<br>«Зилант» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе<br>«Ялкын», «Атлант» спорт юнәлешендәге яшүсмерләр клублары<br>«КукмараРҮХ» МБУЗ<br>Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы<br>Кукмара муниципаль районындаТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы<br>Кукмара муниципаль районы Мәдәният идарәсе<br>Инфраструктура үсеше идарәсе<br>Район эчке эшләр бүлеге<br>Авыл җирлекләре<br>Предприятие, учреждениеләр, оешмалар, иҗтимагый оешмалар<br>«Хезмәт даны» район газетасы редакциясе<br>ТРК «Кукмара авазы» |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның максатлары | Районда физик культура, спортны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру.<br>Халык арасында массакүләм һәм индивидуаль физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшенең үсеше өчен шартлар тудыру, сәламәт яшәү рәвешен раслау, халыкның сәламәтлеген яхшырту. |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Массакүләм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, районның спорт имиджын үстерү.<br>2. Яшьләр һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү | Программа республика һәм муниципаль бюджетлар, бюджеттан тыш чыганаклар, ведомство карамагына бәйсез рәвештә предприятие һәм оешмалар акчалары хисабына тормышка ашырыла. |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы | Программаны тормышка ашыруны координацияләү һәм контрольдә тоту өчен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы Физик культура һәм спорт буенча Координация советыт төзелә. |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленеп, программаны финанслау күләме | 2018 – 2020 елларда Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 96 680,3 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2018 ел – 2 439,2 мең сум;<br>2019 ел – 47 432,5 мең сум;<br>2020 ел – 46 808,6 мең сум;<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Чараларны гамәлгә ашыру 2020 елга кадәр түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>физкультура һәм спорт өлкәсендә:<br>халыкның гомуми санында физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халыкның өлешен 44% ка кадәр;<br>укучылар һәм студентларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче укучылар һәм студентларның өлешлен 61% ка кадәр;<br>Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче инвалидларның әлеге категориядәге халыкның гомуми санындагы өлешен 13% ка кадәр;<br>спорт объектларының бер үк вакытта үткәрүчәнлек сәләтен 36,33 процентка кадәр;<br>спорт корылмалары санын 165 кә кадәр; |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |

**«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү»**
**Ярдәмче программасы чаралары**

| №№ т/б | Чаралары | Башкаручы | Үтәү вакыты | Финанслау ысулы, чыганагы | Чыгымнар суммасы еллар буенча (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| **1. ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ СИСТЕМАСЫН КАМИЛЛӘШТЕРҮ** | | | | | | | |
| 1.1. | Физкультура һәм спорт мәсьәләләре буенча Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Башкарма комитет каршында Координация советы төзү | Башкарма комитет, УДМС | 2018 елның гыйнвар ае | - | - | - | - |
| 1.2. | Физкультура һәм спорт мәсьәләләре буенча программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Башкарма комитет каршындагы Координация советы утырышларын уздыру | Координация советы | Квартал саен | - | - | - | - |
| 1.3. | Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм эш оештыру мәсьәләләре буенча Физкультура активының киңәшмәләрен уздыру | Эчке эшләр бүлеге, Координация советы | Ел саен IV квартал | - | - | - | - |
| 1.4. | Укучыларның физик әзерлеге һәм физик үсеше мониторингын үткәрү | РОО, ГАУЗ «Кукмара РҮХ» | Ел саен | - | - | - | - |
| 1.5. | Районның сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә, авыл җирлекләрендә спорт буенча инструкторларның штат берәмлекләрен кертү | Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре, авыл җирлеге башлыклары | Период дәвамында | - | - | - | - |
| 1.6. | Районның белем бирү учреждениеләре, предприятиеләре, авыл җирлекләре арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм эшен иң яхшы куюга конкурслар оештыру һәм үткәрү | Координация советы, предприятиеләр, АҖ | Ел саен | Муниципаль бюджет (УДМС) | 100 | 125 | 150 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.7. | Район массакүләм мәгълүмат чараларында физкультура, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше темасына иң яхшы публикация, мәкалә, репортажга журналистлар арасында конкурс үткәрү | Координация Советы, район газетасы редакциясе, «Кукмара авазы» ТРК | Ел саен | Муниципаль бюджет (УДМС ) | 10 | 15 | 20 |
| **2. ФИЗКУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ КАДРЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ, ЯҢАДАН ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ КВАЛИФИКАЦИЯЛӘРЕН КҮТӘРҮ** | | | | | | | |
| 2.1. | Спорт төрләре буенча районга кирәкле профессиональ белгечләр әзерләү, шул исәптән максатчан контракт нигезендә | УДМС, РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет (УДМС) | 20 | 30 | 40 |
| 2.2. | Районда кадрларны ныгыту өчен шартлар тудыру (торак, хезмәт хакы) | Башкарма комитет, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре, УДМС, РОО, АҖ | Период дәвамында | - | - | - | - |
| 2.3. | Булган физкультура һәм спорт белгечләрен яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү өчен шартлар тудыру | УДМС, РОО | Период дәвамында | Муниципаль бюджет (УДМС) | 30 | 40 | 50 |
| 2.4. | Мәктәпләрдә һөнәри юнәлеш бирү эшен үткәрү | РОО, УДМС | Период дәвамында | - | - | - | |
| 2.5. | Хезмәт коллективларында физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыру буенча методик рекомендацияләр әзерләү һәм тарату | Координация советы, УДМС | Ел саен | Муниципаль бюджет (УДМС) | | | |
| **3. СПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН ҮСТЕРҮ ҺӘМ БУЛГАН СПОРТ ОБЪЕКТЛАРЫНЫҢ МАТДИ-ТЕХНИК БАЗАСЫН НЫГЫТУ** | | | | | | | |
| 3.1. | «Атлант» ПК капиталь ремонт үткәрү һәм спорт инвентаре белән тәэмин итү | Башкарма комитет | 2018 ел | Муниципаль бюджет | | | |
| 3.2. | Кукмара шәһәрендә, Ошторма-Юмья, Мәмәшир һәм Березняк авыл җирлекләре территориясендә универсаль спорт мәйданчыклары төзү | Башкарма комитет | 2018 ел | Республика бюджеты | | | |
| 3.3. | Урта Комар һәм Важашур авыл җирлекләре территориясендә универсаль спорт мәйданчыклары төзү | Башкарма комитет | 2019 ел | Республика бюджеты | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.4. | Ятмас Дусай авыл җирлеге, Күкшел авылы территориясендә универсаль спорт мәйданчыклары төзү | Башкарма комитет | 2020 ел | Республика бюджеты | | | |
| 3.5. | Тау чаңгысы спортын үстерү. | Башкарма комитет | 2018 – 2020 еллар | Республика һәм муниципаль бюджетлар | | | |
| 3.6. | «Нараткай» балалар җәйге сәламәтләндерү лагеренда 68 урынга исәпләнгән торак корпус төзелеше | Башкарма комитет | 2018-2019 еллар | Республика бюджеты | | | |
| 3.7. | «Зилант» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә капиталь ремонт үткәрү | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Республика һәм муниципаль бюджетлар | | | |
| 3.8. | Кукмара шәһәрендә спорт комплексы төзелеше | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Республика һәм муниципаль бюджетлар | | | |
| 3.9. | Кукмара шәһәрендә тренажер залы булган бассейн төзелеше | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Республика һәм муниципаль бюджетлар | | | |
| 4.0. | Кукмара шәһәрендә чаңгы-роллер трассасын төзү | Башкарма комитет | 2018-2020 еллар | Республика һәм муниципаль бюджетлар | | | |
| **4. Мәктәпкәчә белем бирү системасында физик культураны үстерү** | | | | | | | |
| 4.1.1. | Балаларга физик тәрбия бирү буенча мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре | РОО, ИМЦ | Период дәвамында | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшен активлаштыру | | | | | | |
| 4.1.2. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен спорт җиһазлары һәм инвентарь белән тәэмин итү | РОО | Период дәвамында | Муниципаль бюджет | | | |
| | Балаларның физик сәламәтлеге мәсьәләләре буенча балалар бакчасы каршындагы ата-аналар өчен консультация пунктлары булдыру һәм аларның эшен оештыру | Балалар бакчасы администрациясе | Период дәвамында | - | | | |
| 4.1.3. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәламәтлеге торышын комплекслы мониторинглауны оештыру | РИО, ИМЦ, УДМС | Период дәвамында | - | | | |
| 4.1.4. | Массакүләм мәгълүмат чараларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга физик тәрбия бирүгә, гаиләдә сәламәт яшәү рәвешенә багышланган махсус тапшырулар һәм публикацияләр оештыру | РОО, ИМЦ, УДМС, «Хезмәт даны» газетасы редакциясе, ТРК «Кукмара авазы» | Период дәвамында | - | - | - | |
| 4.1.5. | Массакүләм спорт-сәламәтләндерү чаралары үткәрү | РОО, ИМЦ, МДОУ, УДМС | Период дәвамында | Муниципаль бюджет (РОО) | - | - | |
| **4.2. Мәктәп белем бирү системасында физик культураны үстерү** | | | | | | | |
| 4.2.1. | Укучыларның физик торышын билгеләү буенча мониторинг үткәрү | РОО, «Кукмара РҮХ» МБУЗ | Ел саен | - | - | - | |
| 4.2.2. | Укучыларны физик культура һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча кулланма, рекомендацияләр, күрсәтмә агитация белән тәэмин итү | РОО | Период дәвамында | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.3. | «Спорт һәм сәламәтлек» даими эшләүче лекториен оештыру | РОО | Период дәвамында | - | - | - | |
| 4.2.4. | Укучыларны физик тәрбияләү мәсьәләләре буенча семинарлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр үткәрү | РОО | Квартал саен | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.5. | Физик культура укытучылары өчен | РОО | Системалы | Муниципаль | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәҗрибә уртаклашу буенча семинар, мастер-класслар уздыру | | | бюджет | | | |
| 4.2.6. | «Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшен оештыру буенча иң яхшы мәктәп», «Иң яхшы физик культура укытучысы» бәйгеләрен үткәрү | Координация советы, РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет (РОО) | | | |
| 4.2.7. | «Физик культура» фәне буенча мәктәп укучыларының район олимпиадасын үткәрү | РОО | Ел саен | Муниципаль | | | |
| 4.2.8. | Район мәктәпләрен белем бирү стандартлары нигезендә кирәкле спорт инвентаре һәм җиһазлар белән тәэмин итү | РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.9. | Мәктәп территориясендә спорт корылмаларын ремонтлау, реконструкцияләү, төзү | РОО | Период дәвамында | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.10. | Мәктәпләрдә массакүләм физкультура-сәламәтләндерү спорт чараларын үткәрү | РОО, УДМС, мәктәп администрацияләре | Период буе ай саен | - | - | - | |
| 4.2.11. | Төрле спорт төрләре буенча секцияләр эшен оештыру һәм алар 1-11 сыйныф укучыларын колачлау | РОО, УДМС, мәктәп администрацияләре | Период дәвамында | - | - | - | |
| 4.2.12. | Спорт өлкәсендә сәләтле балаларны бүләкләү | РОО | Период дәвамында | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.13. | Иң яхшы тренер-укытучыларны һәм физкультура укытучыларын бүләкләү | РОО, УДМС, МБУДО ДЮСШ «Зилант» | Период дәвамында | Муниципаль бюджет (РОО, УДМС) | 100 | 150 | 200 |
| 4.2.14. | 8 нче төрдәге Мәчкәрә коррекция мәктәбендә тәрбияләнүчеләр арасында Спартакиада үткәрү | РОО | Елга бер тапкыр | Муниципаль бюджет | 20 | 25 | 30 |
| 4.2.15. | Спортның уен төрләре, милли көрәш, гер спорты, шашка-шахмат, өстәл теннисы буенча куст һәм район ярышлары уздыру | УДМС | Ел саен, график буенча | Муниципаль бюджет | 100 | 150 | 200 |
| 4.2.16 | ТР укучылары Спартакиадасында | РОО, УДМС, | 2 елга бер | Муниципаль | 550 | 650 | 700 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| . | катнашу | МБУДО ДЮСШ «Зилант», ДОО(П)Ц | тапкыр | (РОО, УДМС) | | | |
| 4.2.17. | «Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт юнәлешендәге уку һәм укудан тыш формалар буенча педагогик хезмәт мастеры» Бөтенроссия конкурсының район этабы | РОО | Ел саен | Муниципаль | | | |
| 4.2.18. | Гомуми белем бирү учреждениеләре арасында спортның уен төрләрен үстерүне иң яхшы куюга район конкурсы | РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.19. | Иртәнге зарядкалар, дәресләрдә физкультминуткалар, укучылар һәм укытучылар өчен тәнәфесләрдә музыкалы хәрәкәтчән уеннар үткәрү | Гомуми белем бирү учреждениеләре администрациясе | Даими | - | - | - | |
| 4.2.20. | Физик культура һәм сәламәтлек саклау технологияләре буенча методик эшләнмәләр конкурсының район этабы | РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.21. | «Наркотиклар урынына спорт» район конкурсы | РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.2.22. | Гомуми белем бирү учреждениеләре педагогик хезмәткәрләренең район Спартакиадасы | РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет | | | |
| **4.3. Башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү системасында физик культураны үстерү** | | | | | | | |
| 4.3.1. | Башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү системасында укучыларның физик торышын билгеләү буенча мониторинг үткәрү | Белем бирү учреждениеләре администрациясе | Ел саен | - | - | - | |
| 4.3.2. | Башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү системасы учреждениеләрен типлаштырылган спорт җиһазлары һәм инвентарь белән тәэмин итү | Белем бирү учреждениеләре администрациясе, РОО | Период дәвамында | Муниципаль бюджет (РОО) | | | |
| 4.3.3. | Һөнәри училище һәм техникум укучыларына физик тәрбия бирүнең иң яхшы куелышына конкурс үткәрү | Белем бирү учреждениеләре администрациясе, | Ел саен | Муниципаль бюджет (РОО) | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | РОО | | | | | |
| 4.3.4. | Белем бирү учреждениеләре территориясендә яссылык спорт корылмаларын ремонтлау, реконструкцияләү, төзү | РОО | Период дәвамында | Муниципаль бюджет | | | |
| 4.3.5. | Һөнәри училищелар һәм Лубян лицее укучылары арасында ярышлар оештыру һәм үткәрү | Белем бирү учреждениеләре администрациясе, РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет (РОО) | | | |
| 4.3.6. | Физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнү өчен училищелар тулай торакларында шартлар тудыру (бүлмәләр бүлеп бирү һәм инвентарь белән җиһазлау) | Белем бирү учреждениеләре администрациясе | Период дәвамында | - | - | - | |
| 4.3.7. | Спорт өлкәсендә сәләтле яшьләрне бүләкләү | РОО | Ел саен | Муниципаль бюджет | | | |
| **4.4. Район предприятиеләрендә һәм оешмаларында физик культураны үстерү** | | | | | | | |
| 4.4.1. | Физик сәламәтлек торышын билгеләү өчен предприятие һәм учреждение хезмәткәрләрен диспансерлаштыру | Предприятие һәм учреждениеләр администрациясе, «Кукмара РҮХ» МБУЗ | Ел саен | - | - | - | |
| 4.4.2. | Физик культура белән системалы рәвештә шөгыльләнүче производствода эшләүчеләрне матди кызыксындыру системасын гамәлгә кертү | Предприятие һәм учреждениеләр администрациясе | Период дәвамында | Предприятие һәм оешмалар чаралары | - | - | |
| 4.4.3. | Предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә эш көне режимында физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыру өчен бүлмәләр булдырырга тәкъдим итәргә (мәсәлән. производство гимнастикасы үткәрү, теннис өстәлләре урнаштыру һ. б.) | Предприятие һәм учреждениеләр администрациясе | Период дәвамында | - | - | - | |
| 4.4.4. | Предприятие хезмәткәрләре Спартакиадасын оештыру һәм үткәрү | Координация советы, УДМС | Ел саен | Муниципаль бюджет | 100 | 130 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | (УДМС) | | | 150 |
| **4.5. Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында физик культураны үстерү** | | | | | | | |
| 4.5.1. | Физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт объектларында физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен кирәкле шартлар тудыру (пандуслар урнаштыру, халыкка түләүле хезмәт күрсәтүдә инвалидлар өчен ташламалар, авыл җирендә яшәүче физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен спорт объектларына бару өчен автотранспорт бүлеп бирү һ. б. лар.) | Район һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары, УДМС | Период дәвамында | Авыл җирлекләре бюджетлары | 100 | 150 | 200 |
| 4.5.2. | Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында массакүләм чаралар үткәрү (спортның аерым төрләре буенча ярышлар, спартакиада) | УСЗ МТиЗ РТ, УДМС, Инвалидлар советы | Период дәвамында | Муниципаль бюджет (УДМС) | 300 | 350 | 400 |
| 4.5.3. | Мәчкәрә коррекцион мәктәбендә спорт олимпиадасын үткәрү | РОО, ДОО(П)Ц | Ел саен | Муниципаль бюджет (РОО) | | | |
| **5. РАЙОН МАССАКҮЛӘМ ФИЗКУЛЬТУРА-СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ ҺӘМ СПОРТ ЧАРАЛАРЫН ОЕШТЫРУ** | | | | | | | |
| 5.1. | Укучылар арасында «Алтын алка» хоккей ярышлары | РОО, ДОО(П)Ц | Ел саен гыйнвар-февраль | Муниципаль бюджет (РОО) | | | |
| 5.2. | Район Башлыгы Кубогына өлкәннәр арасында хоккей ярышлары | УДМС | Ел саен гыйнвар-февраль айларында | Муниципаль бюджет | 20 | 30 | 40 |
| 5.3. | Район башлыгы Кубогына өлкәннәр арасында милли көрәш буенча ярышлар | УДМС | Ел саен гыйнвар-февраль айларында | Муниципаль бюджет | 74,3 | 100 | 120 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.4. | Хәрби хезмәткә чакырылуга кадәрге һәм армиягә чакырылучы яшьләр арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча ярышлар | Эчке эшләр бүлеге, РОО, РВК | Ел саен февраль, сентябрь | Муниципаль бюджет (УДМС) | 10 | 15 | 20 |
| 5.5. | Әфганстанда һәлак булган якташларыбыз истәлегенә чаңгы ярышлары | УДМС, РОО, Әфган ветераннары Советы | Ел саен февраль | Муниципаль бюджет (УДМС) | 10 | 10 | 10 |
| 5.6. | «Россия чаңгы юллары» кысаларында «Кукмара чаңгы юлы» ярышлары | УДМС | Ел саен февраль | Муниципаль бюджет | 20 | 25 | 30 |
| 5.7. | Җиңү көненә багышланган җиңел атлетика кроссы | УДМС, авыл җирлеге башлыклары, предприятие һәм учреждение җитәкчеләре | Ел саен май | Муниципаль бюджет (УДМС) | 20 | 25 | 30 |
| 5.8. | Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында район спартакиадасы. | Эчке эшләр бүлеге, УСЗ МТиЗ РТ, Инвалидлар советы | Ел саен июнь | Муниципаль бюджет (УДМС) | 50 | 55 | 60 |
| 5.9. | Балаларны яклау көне, Яшьләр көне, Республика көне һ. б. кысаларында спорт чаралары | УДМС, ОК, РОО | Ел саен июнь | Муниципаль бюджет (УДМС) | 20 | 25 | 30 |
| 5.10. | Балалар арасында «Күн туп» футбол буенча ярышлар | ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ ҮЗӘГЕ, РОО, УДМС | Ел саен июнь ае | Муниципаль бюджет | 50 | 75 | 100 |
| 5.11. | Физкультурачылар көне кысаларында спорт чаралары | УДМС | Ел саен август | Муниципаль бюджет | 50 | 75 | 100 |
| 5.12. | Республика Көнен бәйрәм итү кысаларында спорт чаралары | УДМС | Ел саен август | Муниципаль бюджет | 50 | 75 | 100 |
| 5.13. | Бөтенроссия йөгерү көне кысаларында «Милләтләр кроссы» көзге җиңел атлетика | УДМС | Ел саен сентябрь | Муниципаль бюджет | 50 | 75 | 100 |
| 5.14. | Халыклар бердәмлеге көненә багышланган волейбол буенча район турниры | УДМС | Ел саен ноябрь | Муниципаль бюджет | 50 | 75 | 100 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.15. | Өлкәннәр арасында өстәл теннисы буенча район беренчелеге | УДМС | Ел саен Елга 2 тапкыр | Предприятие һәм оешмалар чаралары | 50 | 75 | 100 |
| 5.16. | «Сабантуй», «Кышны озату» һ. б. массакүләм бәйрәмнәр кысаларында спорт чараларын уздыру | ОК, Кукмара ш.т.п. Башкарма комитеты УДМС | Ел саен период дәвамында | Муниципаль бюджет | 400 | 450 | 490 |
| 5.17. | Һөнәри бәйрәмнәр кысаларында спортның төрле төрләре буенча ярышлар (Төзүчеләр Көне, Медиклар көне һ. б.) уздыру | Предприятие һәм оешма администрациясе, УДМС | Ел саен период дәвамында | Предприятие һәм оешмалар чаралары | 200 | 250 | 300 |
| 5.18. | Яшүсмерләр һәм яшьләр арасында бокс буенча ачык турнир үткәрү | УДМС | Ел саен март аенда | Муниципаль бюджет | 25 | 30 | 35 |
| **6. МӘГЪЛҮМАТИ-АНАЛИТИК ҺӘМ ПРОПАГАНДА ЭШЧӘНЛЕГЕ** | | | | | | | |
| 6.1. | Районда физик культура һәм спортны үстерү буенча статистик тикшеренүләр үткәрү | Эчке эшләр бүлеге, РОО | Ел саен | - | - | - | - |
| 6.2. | «Хезмәт даны» район газетасы битләрендә «Спорт» рубрикасында районның физкультура һәм спорт тормышын яктырту | «Хезмәт даны» район газетасы редакциясе, «Кукмара авазы» ТРК | Период дәвамында | - | - | - | - |
| 6.3. | Җирле радиода халыкның физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүгә кызыксынуын арттыру буенча реклама эшчәнлеге | ТРК «Кукмара авазы» | Период дәвамында | - | - | - | - |
| 6..4. | «Кукмара авазы» («Голос Кукмора») радиосында спорт тематикасына тапшырулар циклын оештыру | Җирле матбугат чаралары | Период дәвамында | - | - | - | - |
| 6.5. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы район массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар бастырып чыгару | Җирле матбугат чаралары | Период дәвамында | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.6. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мәгълүмат урнаштыру өчен реклама щитлары урнаштыру | Координация советы, УДМС | Период дәвамында | Муниципаль бюджет (УДМС) | - | - | - |
| БАРЛЫГЫ: | | | | | 2439,2 мең сум | 47432,5 мең сум | 46808,6 мең сум |

Шартлы кыскартулар билгеләнеше:

"Кукмара РҮХ» МБУЗ –«Кукмара районы үзәк  хастаханәсе» муниципаль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе

УСЗ МТиЗ РТ – ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе

УДМС – Кукмара муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге

РОО – Кукмара муниципаль районы Мәгариф бүлеге

ОК - Кукмара муниципаль районының Мәдәният бүлеге

ИМЦ – Мәгълүмати-методик үзәк

ДОО(П)Ц – Мәктәпкәчә белем бирү үзәге-балалар белем бирү-сәламәтләндерү (профиль) үзәге

МДОУ – Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

СП – Авыл җирлекләре

«Кукмара авазы» ТРК – «Кукмара авазы» телерадиокомпаниясе

ДЮСШ «Зилант» – «Зилант» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе

РВК – Кукмара муниципаль районы Хәрби комиссариаты

ММЧ (СМИ) – Массакүләм мәгълүмат чаралары

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 10.02.2020 елның 134 номерлы карарына 2 нче кушымта

**«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру» Ярдәмче программасы**

1. Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказчы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МУ |
| Ярдәмче программаның төп башкаручылары | Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы;<br>Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Территориаль үсеш бүлеге;<br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МУ;<br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ;<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе (килешү буенча);<br>«Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча);<br>Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе;<br>Кукмара муниципаль районы буенча Эчке эшләр бүлеге (килешү буенча);<br>«Кукмара үзәк район хастаханәс» муниципаль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе;<br>Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Федераль хезмәт Идарәсенең территориаль бүлеге (килешү буенча)<br>Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең Кукмара муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге (килешү буенча). |
| Ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары | Балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру, сәламәтләндерү эффектын арттыру өчен шартлар тудыру. |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Иҗади яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен стационар һәм палатка лагерьларында профильле сменалар оештыру.<br>2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыру.<br>3. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль оешмалардан тыш) хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру. |
| Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 21665,2 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2018 ел – 6770,3 мең сум;<br>2019 ел – 7275,2 мең сум;<br>2020 ел – 7619,7 мең сум.<br><br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерергә тиеш.<br>Бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларны каникул вакытында ял һәм сәламәтләндерүнең төрле формалары белән 31 процент дәрәҗәсендә тәэмин итү.<br>Ял сыйфатын һәм сәламәтләндерү дәрәҗәсен арттыру, барлык программа чаралары буенча чагылдырылган 79 проценттан да ким булмаган сәламәтләндерү нәтиҗәлелегенә ирешү. |

## 2. Расланган хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары нигезендә әлеге Ярдәмче программа кысаларында үткәрелә торган чаралар

| Чараларның исеме | Үтәлү вакыты | Кеше саны | Оештыру өчен җаваплы (башкаручы) |
|---|---|---|---|
| 21 көн дәвам итә торган көндезге (мәктәп яны) лагерьларда каникул вакытларында сменалар оештыру. | 2018 – 2020 еллар | 1040 | «Галактика» балалар иҗаты үзәге» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль учреждениесе директоры Гомәров Альберт Раиф улы |
| 7 көн дәвам итә торган көндезге (мәктәп яны) лагерьларда каникул вакытларында сменалар оештыру. | 2018 – 2020 еллар | 300 | «Галактика» балалар иҗаты үзәге» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль учреждениесе директоры Гомәров Альберт Раиф улы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кукмара муниципаль районының «Нараткай» җәйге сәламәтләндерү лагере» муниципаль бюджет учреждениесендә профильле 18 көнлек сменалар. | 2018 – 2020 еллар | 170 | «Нараткай» җәйге сәламәтләндерү лагере» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Хәкимуллин Әмир Гомәр улы. |
| Кукмара муниципаль районының «Нараткай» җәйге сәламәтләндерү лагере» муниципаль бюджет учреждениесендә профильле 18 көнлек сменалар. | 2018 – 2020 еллар | 255 | «Нараткай» җәйге сәламәтләндерү лагере» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Хәкимуллин Әмир Гомәр улы |
| Хезмәт һәм ял лагерьларын оештыру. | 2018 – 2020 еллар | 50 | «Галактика» балалар иҗаты үзәге» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль учреждениесе директоры Гомәров Альберт Раиф улы |
| Барлыгы | | 1815 | |

### 3. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга субсидияләр

Татарстан Республикасы бюджетыннан балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга субсидияләр – 21 665,2 мең сум , шул исәптән
2018 ел – 6770,3 мең сум;
2009 ел – 7275,2 мең сум;
2020 ел – 7619,7 мең сум.

Искәрмә:

балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 916 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә күрсәтелгән һәм тиешле исәп-хисап ясалган

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 10.02.2020 елның 134 номерлы карарына 3 нче кушымта

**«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы**

**Кукмара муниципаль районының авыл яшьләре» Ярдәмче программасы**

1. **Ярдәмче программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының авыл яшьләре» Ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказчы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны башкаручылар | ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе<br>ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе<br>Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча)<br>ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе<br>ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Территориаль үсеш бүлеге<br>ТР АМО Кукмара бүлекчәсе |
| Ярдәмче программаның төп эшләүчесе | ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе |
| Ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру |
| Ярдәмче программаның бурычлары | 1. Авыл яшьләрен мәгълүмат белән тәэмин итү системасын булдыру.<br>2. Авыл яшьләренең социаль активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.<br>3. Авыл яшьләренең икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.<br>4. Авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме | 2018 – 2020 елларга Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 44 785,2 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2018 ел – 13 688,4 мең сум;<br>2019 ел – 14 957,9 мең сум;<br>2020 ел – 16 138,9 мең сум. |

| | |
|---|---|
| | Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2020 елга кадәр түбәндәгеләрне арттыру күздә тотыла:<br>авыл яшьләренең барлык консультация төрләре (шәхси, электрон, телефон) белән колачланган чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 56,7% ка кадәр;<br>«Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы эшчәнлегенә җәлеп ителгән 15-30 яшьләрдәге яшьләрнең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 60,6 процентка кадәр.<br>җирле советларда авыл яшьләренең өлешен 10,9 процентка кадәр;<br>социаль проектлаштыру буенча белем алган авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 23% ка кадәр;<br>авылны социаль үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 64,2 процентка кадәр;<br>бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәнгән авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 28,4 процентка кадәр;<br>авылны икътисадый үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 10,6% ка кадәр;<br>интеллектуаль-иҗади чараларга җәлеп ителгән авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 63,7% ка кадәр;<br>физкультура-сәламәтләндерү чараларына җәлеп ителгән авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 66,3% ка кадәр;<br>сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 76,5% ка кадәр;<br>һөнәри юнәлеш бирү буенча ярдәмче программа чараларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма саны авыл яшьләренең гомуми санына карата 10,6% ка кадәр |

## I. ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММА ХӘЛ ИТҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ПРОБЛЕМАНЫҢ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Хәзерге вакытта Кукмара муниципаль районында 51,3 меңгә якын кеше яши. 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр саны 12 меңгә якын, бу район халкының 25 процентын тәшкил итә.

Авыл яшьләре, социаль төркем буларак, барлык заман яшь буынының үсеш дәрәҗәсен аның барлык проблемалары белән тасвирлый торган халыкның яшь төркемен төзи. Авылда алар тагын да ачыграк күренә. Икътисади кризис шартларында авылда яшьләрне эшкә урнаштыру мәсьәләләре тагын да актуальләшә бара. Килеп туган хәлне аңлап, яшьләр үз потенциалларын тормышка ашыруның барлык яңа ысулларын эзли башлый. Бүгенге көндә авыл яшьләре арасында проект эшчәнлеген үстерү һәм эшмәкәрлекне үстерү мөһим бурыч булып тора. Кече һәм урта бизнес районның икътисадта һәм социаль өлкәдә инновацион үзгәрешләрнең ышанычлы терәге булган урта сыйныфны формалаштырырга тиеш. Моның өчен башта авылда

үзмәшгульлек һәм кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләрен хәл итү максатында бизнес-планлаштыруның элементар күнекмәләренә өйрәтү таләп ителә. Хәзер моны Интернет челтәре ярдәмендә дистанцион укыту һәм вебинарлар программаларыннан файдаланып башкарырга мөмкин.

Районның төрле өлкәләрдә (мәгариф, сәламәтлек саклау, элемтә, транспорт һ.б.) социаль-икътисади үсеше, яшәү рәвешен модернизацияләү һәм эшчәнлекнең перспективалы юнәлешләре нәтиҗәсендә аларның җәлеп итүчәнлеген арттыру нәкъ менә авыл җирендә үз киләчәген төзергә теләгән авыл яшьләре өчен оптималь мөмкинлекләр булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

## II. ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ, ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ, КӨТЕЛГӘН СОҢГЫ НӘТИҖӘЛӘРНЕ ТАСВИРЛАУ, АНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ВАКЫТЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

Программаның максаты – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

Авыл яшьләрен мәгълүмат белән тәэмин итү системасын булдыру авыл яшьләренә массакүләм мәгълүмат чаралары, мәгълүмат-полиграфия продукциясе аша, шулай ук IT-технологияләрне куллану юлы белән махсус җайлаштырылган мәгълүмат җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.

Авыл яшьләренең социаль активлыгын арттыру өчен шартлар тудыруны, авыл яшьләре мәсьәләләре белән шөгыльләнүче яшьләр оешмаларын булдыруны, авыл яшьләренең иҗтимагый-сәяси активлыгын күтәрүне, авыл яшьләрен социаль проектлауга өйрәтүне һәм яшьләрне авылны социаль үстерү программаларын тормышка ашыруга җәлеп итүне күздә тота.

Авыл яшьләренең икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру авыл яшьләрен бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәтүне, авыл җирендә яшьләрне эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүне һәм яшьләрне авылны икътисадый үстерү программаларын гамәлгә ашыруга җәлеп итүне үз эченә ала.

Авыл яшьләренең рухи, физик һәм иҗади үсешенә ярдәм итү интеллектуаль-иҗади һәм физкультура-сәламәтләндерү чараларын оештыруны һәм үткәрүне, шулай ук яшүсмерләр һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга ярдәм итүне күздә тота.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру срогы – 2018 – 2020 еллар.

## III. ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль заказчы булып тора.

Программаны башкаручылар:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе.
- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Кукмара районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (килешү буенча)

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе.
- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге.
- ТР АМО Кукмара бүлекчәсе

Ярдәмче программаның үтәлешен ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты гомуми контрольдә тота.

## IV. ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАНЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ, СОЦИАЛЬ ҺӘМ

# ЭКОЛОГИК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

яшьләр иҗтимагый оешмаларында торучы авыл яшьләре санын арттырырга;

җирле үзидарә органнарында авыл яшьләре өлешен арттырырга;

авылны социаль һәм икътисадый үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләре санын арттырырга;

Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсенә җәлеп ителгән авыл яшьләре санын арттырырга;

авыл яшьләрен социаль проектлаштыру һәм бизнес-планлаштыру нигезләренә өйрәтергә;

югары һөнәри белем алган авыл яшьләре санын арттырырга;

авыл яшьләре өчен интеллектуаль-иҗади чаралар оештырырга;

авыл яшьләре өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары оештырырга;

авыл яшьләренең сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру программаларында катнашуын арттырырга.

Социаль проектлаштыруга, бизнес-планлаштыруга, социаль программаларга өйрәтү авыл яшьләренә грант нигезендә конкурсларда катнашырга, үз эшләрен башларга, аз чыгымлы һәм нәтиҗәле программалар һәм проектлар кертергә мөмкинлек бирәчәк.

Подпрограмматы гамәлгә ашыру кысаларында конкрет белгечләр – яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче Ярдәмче программаны башкаручылар, торак, ташламалы кредитлар, белем алу буенча махсус мәгълүматка ия булып, команда эше, Социаль проектлау, бизнес-планлаштыру, электораль активлыкны күтәрү технологияләреннән файдаланып, Ярдәмче программа бурычларын үтәргә ярдәм итәчәк, эшнең адреслы булуын, авылда социаль, икътисадый программаларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәчәк дип көтелә.

Ярдәмче программа чараларын уңышлы үтәү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

авыл яшьләренең районның социаль-икътисади үсеше белән кызыксынуы һәм аның әлеге процесста катнашырга әзерлеге;

авыл җирлегендә уңай демографик тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту;

авыл җирлегендә социаль киеренкелек дәрәҗәсенең кимүе;

авыл яшьләренең шәһәргә күчүе кимүе;

дәүләт структураларына халыкның ышаныч дәрәҗәсе күтәрелү;

авыл яшьләренең тормыш сыйфаты яхшыру.

**ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ**

<table>
<tr><th rowspan="2">Максатның исеме</th><th rowspan="2">Бурычның исеме</th><th rowspan="2">Төп чараларның исеме</th><th rowspan="2">Башкаручылар</th><th rowspan="2">Төп чараларны башкару сроклары</th><th rowspan="2">Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре</th><th colspan="3">Елы</th></tr>
<tr><th>2018 елы</th><th>2019 ел</th><th>2020 ел</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td></tr>
<tr><td rowspan="5">Татарстан Республикасы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру</td><td rowspan="4">Авыл яшьләрен мәгълүмат белән тәэмин итү системасын булдыру</td><td>Авыл яшьләренә белешмә консультация бирү практикасын тарату, мәгълүмати хезмәт күрсәтү, мәгълүмат продуктлары чыгару</td><td>УДМС УСХиП (килешү буенча), ТР АМО Кукмара бүлекчәсе (килешү буенча)</td><td>2018 – 2020 еллар</td><td rowspan="4">Авыл яшьләренең гомуми санына карата барлык консультация төрләре (шәхси, электрон, телефон) белән тәэмин ителгән авыл яшьләренең чагыштырма саны, %</td><td>25,6</td><td>33,3</td><td>37,5</td></tr>
<tr><td>Кукмара муниципаль районы авыл яшьләренең электрон порталын булдыру</td><td>УДМС, РТ АМО (Кукмара бүлекчәсе)</td><td>2018 – 2020 еллар</td><td rowspan="3"></td><td rowspan="3"></td><td rowspan="3"></td></tr>
<tr><td>Авыл җирлегендә дәүләт яшьләр сәясәте тематикасы буенча методик кулланмалар, реклама видеороликлар булдыруны тәэмин итү</td><td>УДМС, РТ АМО (Кукмара бүлекчәсе)</td><td>2018 – 2020 еллар</td></tr>
<tr><td>Район массакүләм мәгълүмат чараларында авыл яшьләре белән эшне яктырту</td><td>УДМС, РТ АМО (Кукмара бүлекчәсе)</td><td>2018 – 2020 еллар</td></tr>
<tr><td>Авыл яшьләренең социаль активлыгын арттыру</td><td>Кукмара муниципаль районында авыл яшьләре мәсьәләләре белән шөгыльләнүче иҗтимагый</td><td>УДМС</td><td>2018 – 2020 еллар</td><td>«Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы эшчәнлегенә җәлеп</td><td>2,38</td><td>9,52</td><td>47,6</td></tr>
</table>

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өчен шартлар тудыру | оешмаларга билгеләнгән тәртиптә төрле ярдәм күрсәтү | | | ителгән 15-30 яшьләрдәге яшьләрнең чагыштырмача саны авыл яшьләренең гомуми санына карата, % | | | |
| | | Авыл яшьләрен иҗтимагый-сәяси активлыкны үстерү буенча эш технологияләренә өйрәтү | Район авыл җирлекләре (килешү буенча), ТР АМО (Кукмара бүлекчәсе) | 2018 – 2020 еллар | Депутатларның җирле советларында авыл яшьләренең чагыштырма саны, % | 0,6 | 2,7 | 2,7 |
